**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итү турында**

Урта гасырларда яшәгән күренекле шагыйрь, мәгърифәтче һәм гуманист Кол Галинең һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәренең татар язма әдәбияты һәм мәдәнияте үсешенә зур өлеш кертүен исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. 2033 елда Татарстан Республикасында Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуга багышланган чараларны уздырырга.

2. Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә.

3. Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 90 көн эчендә, Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты тәкъдимнәрен исәпкә алып, Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итү чаралары планын эшләргә һәм расларга.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына 2033 елда Татарстан Республикасында Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә 2033 елда Татарстан Республикасында Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итү чараларын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 23 декабрь
№ 905

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «23»декабрендәге
905 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында нигезләмә**

1. Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган чараларны Татарстан Республикасында әзерләү һәм уздыру, шулай ук алда атап үтелгән чараларны уздыруда катнаша торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү максатыннан чыгып төзелде.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планына (алга таба – Чаралар планы) кертү өчен тәкъдимнәр әзерләү;

б) Чаралар планын үтәү бурычларын хәл итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

в) Чаралар планын үтәү һәм аңа үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр эшләү мәсьәләләрен карау.

4. Оештыру комитеты бурычларын үтәү максатыннан:

а) законнар нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан

Республикасы буенча территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән Оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

б) оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә вакытлы эш төркемнәрен булдырырга;

в) үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен чакырырга хокуклы.

5. Оештыру комитеты составын Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

6. Оештыру комитеты составына аның эшендә җәмәгать башлангычында катнашучы оештыру комитеты рәисе, оештыру комитеты рәисе урынбасарлары, оештыру комитеты секретаре һәм оештыру комитеты әгъзалары керә.

7. Оештыру комитеты утырышлары ихтыяҗ туган саен, әмма кимендә елга бер тапкыр уздырыла.

8. Оештыру комитеты утырышларын оештыру комитеты рәисе яки аның кушуы буенча оештыру комитеты рәисе урынбасары үткәрә.

9. Утырышларның көн тәртибен, урынын һәм аларны үткәрү тәртибен оештыру комитеты рәисе билгели.

10. Оештыру комитеты утырышы, әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашкан очракта, эш алып барырга хокуклы дип санала.

11. Оештыру комитеты карарлары утырышта катнашкан оештыру комитеты әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны бертигез булганда, оештыру комитеты утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Оештыру комитеты әгъзасы утырышта катнашмаган очракта, карап тикшерелгән мәсьәләләр буенча үзенең оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә мәҗбүри теркәлергә тиешле фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

12. Оештыру комитеты утырышында мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Оештыру комитеты утырышының беркетмәсенә рәислек итүче кул куя.

13. Оештыру комитеты кабул иткән карарлар кызыксынган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләргә җиткерелә.

14. Оештыру комитеты карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары проектлары әзерләнергә мөмкин.

15. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар һәм мәгълүмат белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тәэмин итә.

______________

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «23» декабрендәге
905 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе, оештыру комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Шәйхразиев Васил Габделгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Низамова Ләйсән Габделхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы, оештыру комитеты секретаре |
| Әминов Илшат Юныс улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Әхмәдиева<br>Роза Шәйхәйдәр кызы | «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Бикчәнтәев<br>Фәрит Рәфкать улы | «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе баш режиссеры, «Россия Федерациясе Театр әһелләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» гомумроссия иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы Театр әһелләре берлеге» төбәк бүлекчәсе рәисе (килешү буенча) |
| Вяткина<br>Алиса Львовна | «Татарстан Республикасы Милли музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе генераль директоры |
| Гыйльметдинов<br>Илдар Ирек улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Милләтләр эшләре Комитеты рәисенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин<br>Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Заһидуллина<br>Дания Фатыйх кызы | филология фәннәре докторы, профессор (килешү буенча) |
| Зәйдуллин<br>Ркаил Рафаил улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) рәисе (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Җиһаншин<br>Рамил Рөстәм улы | «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры |

| | |
|---|---|
| Крылов<br>Анатолий Валентинович | «Россия рәссамнар берлеге» бөтенроссия иҗат иҗтимагый оешмасының «Татарстан Рәссамнар берлеге» төбәк бүлекчәсе рәисе (килешү буенча) |
| Миңнеханов<br>Рифкать Нургали улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президенты |
| Миңнуллин<br>Ким Мөгаллим улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсе директоры |
| Мөхәрләмов<br>Руслан Роберт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Нургалиева<br>Розалия Миргалим кызы | «Татарстан Республикасының Сынлы сәнгать дәүләт музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры |
| Сәгъдәтшин<br>Илдар Камил улы | «Татарстан китап нәшрияты» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры (килешү буенча) |
| Сәгыйтова<br>Гүзәл Рәмзил кызы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Салихов<br>Радик Рим улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры |

| | |
|---|---|
| Сәмигуллин Камил хәзрәт (Сәмигуллин Камил Искәндәр улы) | Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасы рәисе, мөфти (килешү буенча) |
| Тимерҗанова Мәдинә Фатыйх кызы | «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры |
| Һашимова Нурия Миңнеәхмәт кызы | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм итү фонды башкарма директоры (килешү буенча) |
| Шакиров Данис Фәнис улы | Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |

---